РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

---

"22" март 2024 ел　　Вәрәшбаш авылы　　№ 7

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның «29» июлендәге 12 номерлы «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газоннарны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (№15 28.09.2021 елгы үзгәрешләре белән)**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Прокуратурасының 2024 елның 18 мартындагы 02-08-01-2024 номерлы протестын карап чыгып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең башкарма комитетының 2021 елның «29»июлендәге 12 номерлы «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газоннарны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» гы карарына (№15 28.09.2021 елгы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.5.2.1 пунктынын җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советының «24» февраль 2021елның 13 номерлы «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшеллекләрне кисү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына кертелергә тиешле түләүләрне исәпләү өчен билгеләнгән (алга таба – торак пункт) физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге яшеллекләрне законлы рәвештә тартып алганда компенсацион яшелләндерү өчен, шулай ук торак пункт территориясендә урнашкан яшеллекләргә законсыз зыян килү яки юк ителү нәтиҗәсендә компенсация бәясен түләү өчен счет төзи;»;

1.2. 3.5.2.2 пунктының дүртенче абзацында «кирәк булганда» сузләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 3.8 пунктны өстәргә:

«3.8. Муниципаль хезмәтне алдан күрсәтү режимында (проактив режимда) күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү каралмаган.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитеты җитәкчесе З.З.Галиева